проект

Татарстан
Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш), № 79 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), түбәндәге эчтәлектәге $1^1$ өлешне өстәп, үзгәреш кертергә:

«$1^1$. Гавами хакимият системасының бердәмлеге принцибы нигезендә муниципаль район башлыгы һәм шәһәр округы башлыгы бер үк вакытта Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаны билиләр.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2,

№ 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 93 (I өлеш), «, муниципаль районнар башлыкларына һәм шәһәр округлары башлыкларына» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2018, № 1 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләрен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Закон «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләрен күз алдында тота.»;

б) 2 өлешнең 2 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

в) 4 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлектәге $2^1$ статьяны өстәргә:

«$2^1$ статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаны бер үк вакытта биләүче затка бирелә торган өстәмә гарантияләр**

1. Гавами хакимият системасының бердәмлеге принцибы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаны бер үк вакытта биләүче затка әлеге Законның 2 статьясында каралган гарантияләргә өстәмә рәвештә түбәндәге гарантияләр бирелә:

1) еллык түләүле отпуск бирелгәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда елга бер мәртәбә башкарылырга мөмкин булган ике айлык акчалата түләү күләмендә бер мәртәбә акчалата түләү, ул әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән зат теләге буенча башка вакытта алынырга да мөмкин;

2) шифаханә-курортта дәвалану, ял итү урынына бару һәм кире кайту өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда бер айлык акчалата түләү күләмендә бер мәртәбә акчалата түләү;

3) әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, әлеге Закон нигезендә картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә ай саен өстәмә түләү хокукы булган очракта (алга таба - пенсиягә өстәмә түләү) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда биләгән вазыйфа буенча билгеләнгән ун айлык акчалата түләү күләмендә бер мәртәбә акчалата түләү;

4) әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән вазыйфаны биләүнең бөтен чорына бер мәртәбә федераль законнарда, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак сатып алуга бер мәртәбә бирелә торган субсидия.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән зат вафат булган очракта, гаилә әгъзаларына, башка туганнарына яисә аны җирләүче башка затларга җирләү һәм ритуаль хезмәт күрсәтү чыгымнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда каплана.

3. Әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктында каралган нигезләмәләр әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга кагылмый.

4. Әлеге статьяда каралган чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

4) 3 статьяның 2 өлешендәге беренче абзацта «норматив актлары белән» сүзләрен «әлеге Законы һәм башка норматив хокукый актлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта «картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә айлык өстәмә (алга таба - пенсиягә өстәмә)» сүзләрен «пенсиягә өстәмә» сүзләренә, «түбәндәге шартларда» сүзләрен «түбәндәге шартларга бер үк вакытта туры килгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «биләсә» сүзен «биләү» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «азат ителсә» сүзләрен «азат ителү» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «биләсә» сүзен «биләү» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта «җитсә» сүзен «җитү» сүзенә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары» сүзләрен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның» сүзләренә алмаштырырга;

в) $8^{1}$ өлештә «җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының» сүзләрен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2025 елның 19 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. ««Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ статьясы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Закон проекты муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның статусын төгәлләштерүгә һәм муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына гарантияләрне киңәйтүгә юнәлдерелгән.

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 33-ФЗ номерлы Федераль закон) 19 статьясындагы 20 өлешендә гавами хакимият системасының бердәмлеге принцибы нигезендә муниципаль берәмлек башлыгы бер үк вакытта Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаны да били дип карала. Шул ук вакытта  әлеге федераль законның 89 статьясындагы 14 өлешендә җирлекләр башлыкларына карата Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаны бер үк вакытта биләү Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә җирлек уставы нигезендә карала.

33-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 5 өлеше белән муниципаль берәмлек башлыгы өчен әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә билгеләнгән гарантияләргә өстәмә буларак Россия Федерациясе субъекты законы белән Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазыйфасын биләүгә бәйле гарантияләр билгеләнергә мөмкин дип карала.

33-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 20 өлеше нигезендә Закон проекты белән, күрсәтелгән Федераль законның 89 статьясындагы 14 өлеше белән Россия Федерациясе субъектларына җирлек башлыкларына мөнәсәбәттә алар тарафыннан югарыда күрсәтелгән вазыйфаларны бер үк вакытта биләүне мөстәкыйль рәвештә билгеләүгә хокукны гамәлгә ашырып, бары тик муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына гына Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы статусы бирү тәкъдим ителә (1 статья).

2 статья «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә аның гамәлдә булуы муниципаль районнар башлыкларына һәм шәһәр округлары башлыкларына кагылмый дигән төзәтмә кертүне күздә тота.

3 статьяда муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен гарантияләргә охшаш өстәмә гарантияләр кертү карала. Моннан тыш, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куела торган вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Законының аерым нигезләмәләрен актуальләштерү һәм төгәлләштерү күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларының Җыелма исемлеген раслау турында» 2006 елның 9 мартындагы ПУ-92 номерлы Указына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының муниципаль вазыйфаны һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын бер үк вакытта биләүче затларга Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән дәүләт гарантияләре бирү тәртибен һәм шартларын күздә тоткан актларын бастырып чыгару таләп ителәчәк.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарында терминологияне актуальләштерү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан 37 341, 7 мең сум күләмендә өстәмә финанслауны таләп итә.